СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл җирлеге Советы**
**карары**

« 20 » февраль 2023 ел №	72

**Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы, «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы нигезендә Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Расларга:

1.1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне (1 нче кушымта);

1.2. Гражданнар Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткә билгеләнгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм аларны биләгәндә Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге органнары муниципаль хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген (2 нче кушымта).

2. Түбәндәге карарларны үз көчләрен югалткан дип танырга:

2.1. «Наласа авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар

тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Наласа авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» Наласа авыл җирлеге Советының 2014 елның 03 ноябрендәге 74/1 номерлы карарын (19.04.2016 № 17, 03.08.2021 №31, 01.06.2022 № 51үзгәрешләр белән).

2.2 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2016 елның 18 апрелендәге 16 номерлы карарын (01.06.2022 № 52 үзгәрешләр белән)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова

*Арча муниципаль районы*
*Наласа авыл җирлеге Советының*
*"20" февраль 2023 ел, №72*
*карарына 1 нче кушымта*

**Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә**

1. Әлеге нигезләмә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәгеләрне тапшыру тәртибен билгели:

- Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милек хокукындагы мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) турында белешмәләр;

- Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба - керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре) турында белешмәләр.

2. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданның (алга таба - граждан), шулай ук Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең (алга таба - муниципаль хезмәткәр) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычы аны биләүгә дәгъва кылучы граждан яисә аны биләгән муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт вазыйфасы Наласа авыл җирлеге Советының әлеге карарның 2 пункты нигезендә расланган Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасы исемлегенә кертелгәндә йөкләнә.

3. Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, алар вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләнгәндә тапшырыла.

4. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган вазыйфалар исемлегендә каралган белешмә формасы буенча ел саен хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

5. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә граждан түбәндәгеләрне тапшыра:

а) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган үз керемнәре (элеккеге эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук граждан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү аена кадәрге айның беренче числосына (хисап

датасына) милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре (элеккеге эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук граждан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) аларның милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

6. Муниципаль хезмәткәр ел саен түбәндәгеләрне тапшыра:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган үзенең керемнәре (акчалата түләүләр, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай укхисап чоры ахырына торышы буенч милек хокукындагы мөлкәте һәм а мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре (акчалата түләүләр, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай укхисап чоры ахырына торышы буенч милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

в) (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алуга кагылышлы алыш-бирешнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.

7. Вазыйфалар исемлегенә кертелмәгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче һәм вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 2, 3 һәм 5 пунктлары нигезендә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра.

8. Әлеге Нигезләмәнең 5 һәм 6 пунктларында каралган белешмәләр җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгечкә) җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә тапшырыла.

9.Әгәр граждан яисә муниципаль хезмәткәр тарафыннан җирле үзидарә органына (кадрлар эше буенча белгечкә) тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүмат чагылдырылмаган яки тулысынча чагылдырылмаган икән, ул әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

Муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга мөмкин.

9.1. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган «БК белешмәләре» махсус программа тәэмин ителешен файдаланып тутырыла, аңа сылтама шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла.

10. Объектив сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәткәр хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмаган очракта, әлеге факт муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча тиешле комиссиядә каралырга тиеш.

11. Граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

Әлеге белешмәләр җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенә һәм җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларына, вазыйфага билгеләнү һәм муниципаль хезмәткәр вазыйфасыннан азат итү вәкаләтләренә ия булган затларга, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда, башка вазыйфаи затларга тапшырыла.

13. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюталар турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган чорда акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр законнарда билгеләнгән тәртиптә Арча муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

14. Вазыйфаи бурычларына граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган белешмәләр белән эш итү керә торган муниципаль хезмәткәрләр аларны фаш итүдә яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

15. Граждан яисә әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, муниципаль хезмәткәр тарафыннан ел саен тапшырыла торган мәгълүмат һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә.

Җирле үзидарә органының (муниципаль органның) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгечкә) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырган әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән граждан яисә муниципаль хезмәткәр вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, әлеге белешмәләр аларның язма гаризалары буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла.

16. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмаган яисә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшырган очракта, граждан муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнеп куела алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылыкның башка төрләренә тартыла.

Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз чыгымнары турында белешмәләр тапшырмау яки тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырмау яки белә торып тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру, мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булган очракта, билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәттән чыгару, биләгән вазыйфадан азат итүне китереп чыгаручы хокук бозу булып тора.

*Арча муниципаль районы*
*Наласа авыл җирлеге Советының*
*"20" февраль 2023 ел, № 72*
*карарына 2 нче кушымта*

**Гражданнар Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткә билгеләнгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм аларны биләгәндә Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге органнары муниципаль хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге**

| **Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты** | | |
|---|---|---|
| 1 | Башкарма комитет секретаре | 1 вазыйфа |
| | | |